Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559 ) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

РЕШЕНИЕ | КАРАР
17.06.2020 ел | № 182

Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында»гы 27.02.2013 елның 82 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгару өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 2 декабрендәге 396-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясына һәм 39 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Җәлил шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге Уставы белән, 2020 елның 20 маендагы ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә һәм ачык тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркем тәкъдимнәре нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 27.02.2013 елдан 82 номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» гы карарына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы — Р.Ә. Кәримов

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының
17.06.2020 елның 182 нче номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 27 февралендәге 82 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 27.02.2013 ел, №82 карары белән расланган Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 25 статьяда:
1.1. 2 өлешнең 1 пунктына киләсе эчтәлектәге 1.1 пунктчасы өстәргә:
«1.1) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү;»

1.2.  2 өлешнең 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5.1-5.5 пунктчалар өстәргә:
«5.1) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау;
5.2) файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проекты яки җир асты байлыклары участокларыннан файдалануга бәйле эшләрне башкару өчен җир асты байлыклары турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән, килештерелгән һәм расланган бораулау скважиналарын төзү, реконструкцияләү;;
5.3) чит илләрдә Россия Федерациясе илчелекләрен, консуллыкларын һәм вәкиллекләрен төзү, реконструкцияләү;
5.4) 0,6 мегапаскальгә кадәр басым астында табигый газ транспортлау өчен билгеләнгән объектларны төзү, реконструкцияләү;;
5.5) элемтә чараларын урнаштыру өчен билгеләнгән 50 метр биеклектәге антенна терәкләр (мачт һәм башнялар) урнаштыру;»

1.3. 2 өлешнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) башка очракларда, әгәр дә шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә төзелешкә рөхсәт алу таләп ителми.»

2. 26 статьяда:
2.1. 7 өлешнең дүртенче абзацында «ундүрт көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга»

2.2. 1 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, индивидуаль торак төзелеше объектын, бакча йортын төзегәндә, реконструкцияләгәндә проект документациясен әзерләү таләп ителми. Төзүче үз инициативасы белән индивидуаль торак төзелеше объектына, бакча йортына карата проект документациясен әзерләүне тәэмин итәргә хокуклы.»

3. 27 статьяның 8 өлешендәге беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитет, төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алган көннән алып биш эш көне эчендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 11.1 өлешендә каралган очрактан тыш:

- төзелешкә рөхсәт бирү турында Карар кабул итү өчен кирәкле документларның булу-булмавын тикшерә;»

4. 29 статьяның 4 өлешендә «ун көн эчендә» сүзләрен «биш эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга»

5. 36 статьяның 10 өлешендәге өченче абзацында «объектлар,» сүзеннән соң «авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен» сүзләрен өстәргә.